**СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ**
**РАЙОН СОВЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**7 июнь, 2023 ел** **№ 300**

**Биектау районы Советының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге территориясе өлеше - Березовка п. Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» 2023 елның 28 апрелендәге 286 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Территорияне тотрыклы үстерү өчен шартлар тудыру, шәһәр төзелеше эшчәнлеген гамәлгә ашыру тәртибен җайга салу, «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге составына керә торган Березовка п. территориясендә тәртипкә салынган һәм нәтиҗәле җирдән файдалану һәм төзелешне тәэмин итү максатларында, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 32 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Биектау районы Советының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге территориясе өлеше - Березовка п. Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» 2023 елның 28 апрелендәге 286 номерлы карарына (алга таба – Карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә: Карарның 1 пунктын 1.1 пунктчасы белән тулыландырырга: «Кушымтада бирелгән Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре раслануга бәйле рәвештә, 16:16-7.24, 16:16-7.25, 16:16-7.26, 16:16-7.26, 16:16-7.35, 16:16-7.24, 16:16-7.245 реестр номерлы булган территориаль зоналарны гамәлдән чыккан дип танырга һәм аларны "архив" статусына күчерергә».
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Интернет-телекоммуникация челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча һәм Интернет-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Совет рәисе,
муниципаль район Башлыгы Р.Ф.Хисамутдинов